СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 18-21 от «26» апреля 2023 г.

Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, « Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273 ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге № 116-ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге № 181-ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 декабрендәге № 498-ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 28 декабрендәге № 569-ФЗ, «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге № 236-ФЗ, Татарстан Республикасы «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 15.10.2015 елның 15 октябрендәге 4-2 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (12.11.2016 ел, № 3-12, 12.05.2017 ел, № 8-16, 26.07.2017 ел, № 4-18, 13.11.2017 ел, №4-19, 29.06.2018 ел, №10-27, 03.09.2018 ел, № 8-28, 19.11.2018 ел, № 11-29, 28.03.2019 №8-32, 23.07.2019 №17-34, 30.06.2020 №12-39, 10.06.2021 №8-7, 12.11.2021 №13-9 үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 7 бүлегендәге 7.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 11 пункт өстәргә:

«11) аларга чит ил агенты статусын алу.»;

1.2. Нигезләмәнең 7 бүлегендәге 7.1 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгын йә чит ил гражданлыгын (подданлыгын) туктату - Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы.»;

1.3. Нигезләмәнең 12 бүлегендәге 12.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (персональләштерелгән) исәп системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

1.4. Нигезләмәнең 12 бүлегендәге 12.19 пунктының 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

1.5. Нигезләмәнең 24 бүлегендәге 24.2. пунктының 4 пунктчасындагы «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.

1.6. Нигезләмәнең 11 нче бүлегендә:

а) 11.9 пунктта "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен “Татарстан Республикасы Рәисе” сүзләренә алыштырырга;

б) 11.10 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына " дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алыштырырга ;

в) 11.12 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты "сүзләрен “Татарстан Республикасы Рәисе" сүзләренә алыштырырга;

г) 11.13 пунктта "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алыштырырга;

1.7. Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында 2.3 нче пунктта «Татарстан Республикасы Президентына”сүзләрен “ Татарстан Республикасы Рәисенә” сүзләренә алыштырырга;

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе — А.П.Иванов